төзелеш кирәк-ярагын алу һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; зиаратны төзекләндерү һәм карап тору өчен чыгымнар тоту;паркны төзекләндерү һәм карап тоту, парк әйләнәсен чистартып тоту, хезмәтләр өчен түләү,транспорт хезмәтләре өчен түләү, балалар мәйданчыгы өчен инвентарь алу һәм урнаштыру өчен чыгымнар тоту; урам утларын карап тоту, лампочкалар алу өчен чыгымнар тоту..

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Фатыхова А.В.

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“23” ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта, 2019 елның 23 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:.

Түбән Бәрәскә авыл территориясен чистарту һәм төзекләндерү, агачларны кистерү һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; басманы төзекләндерү, төзелеш кирәк-ярагын алу һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; зиаратны төзекләндерү һәм карап тору өчен чыгымнар тоту;паркны төзекләндерү һәм карап тоту, парк әйләнәсен чистартып тоту, хезмәтләр өчен түләү,транспорт хезмәтләре өчен түләү, балалар мәйданчыгы өчен инвентарь алу һәм урнаштыру өчен чыгымнар тоту; урам утларын карап тоту, лампочкалар алу өчен чыгымнар тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 663 (алты йөз алтмыш өч) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан граҗданнар саны 575 (биш йөз җитмеш биш) кеше, бу 86,7 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 575 (биш йөз җитмеш биш) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Сез 2020 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: - Түбән Бәрәскә авыл территориясен чистарту һәм төзекләндерү, агачларны кистерү һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; басманы төзекләндерү,